**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

**«22» января 2025ел** **№ 12**

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 26 декабрендәге 173 номерлы «2025 елга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районыхалкы өчен торак хезмәтләре тарифларын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта тиешле сыйфатта булмаган һәм (яисә) билгеләнгән вакыттан артыграк өзеклекләр белән гомуми мөлкәт белән идарә итү, карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәткән һәм эшләр башкарган очракта торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» карары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2024 елның 14 декабрендәге 962 номерлы «2025 елга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индекслары турында» Указы нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 26 декабрендәге 173 номерлы «2025 елга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районыхалкы өчен торак хезмәтләре тарифларын раслау турында» карарына, кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«26» декабрендәге 173 номерлы
карарына кушымта

2025 елга район халкы өчен торак хезмәтләренә тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең атамасы | Үлч. бер. | Хезмәт күрсәтү үлчәү берәмлеге өчен тариф | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 01.01.2025 алып 30.06.2025 | 01.07.2025 алып 31.12.2025 |

| | | | кадәр | кадәр |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Торак фонды белән идарә итү | кв.м | 4,43 | 6,08 |
| 2. | Торак бинага агымдагы ремонт | кв.м | 4,28 | 4,28 |
| 3. | Йорт яны территориясен тоту (үләннәрне чабу һәм җыю, кардан чистарту, түбәне кардан һәм боздан чистарту) | кв.м | 4,67 | 5,65 |
| 4. | Йорт эчендәге сантехник канализация челтәрләрен агымдагы ремонтлау | кв.м | 2,85 | 3,40 |
| 5. | Йорт эчендәге электр челтәрләрен агымдагы ремонтлау | кв.м | 1,62 | 1,62 |
| 6. | Су белән тәэмин итүнең гомумйорт системаларын агымдагы ремонтлау | кв.м | 0,64 | 0,64 |
| 7. | Төтенлекләргә техник хезмәт күрсәтү | кв.м | 0,50 | 0,60 |
| 8. | Вентиляция каналларына техник хезмәт күрсәтү | кв.м | 0,50 | 0,60 |
| 9. | Фасад газүткәргечләрен ремонтлау һәм аларны карап тоту | кв. м. | 0,44 | 0,53 |
| 10. | Дератизация | кв.м | 0,15 | 0,15 |

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин